

Әле генә жирле vзидарә конен муниципалитетларнын башкарма һәм вәкиллекле хакимият органнары хез-мәткәрләре билгеләп vтте. Язмабыз шул олкә кешесе турында. Торбеево районы Такташлы Сыркыды (Сургодь) авылында 2012 елнын мартыннан бирле жирлек башлыгы вазыйфасын Фәрит Тагер улы Эртуганов башкара. Ун елдан сон да анын максатлары vзгәрешсез кала: авыл халкынын тормыш сыйфатын яхшырту һәм жиде йоз утыз кеше яшәгән территориянен социаль - икътисади vсешен тәэмин итv. Аларнын һәрберсе белән тыгыз хезмәттәшлектә конvзәк мәсьәләләр хәл ителә, киләчәккә планнар тозелә, ин кыю идеяләр һәм ижтимагый әһәмиятле инициативалар тормышка ашырыла.      Фәрит Тагер улы әйткәнчә, торак пунктта барлык йортлар да тулысынча газлаштырылган һәм су белән тәэмин ителгән, яхшы юллар бар, интернет челтәре салынган, кон тәртибеннән кайбер конvзәк мәсьәләләрне алып ташлау момкинлеге бирә торган vзара салым системасы эшли, хужасыз жирләрне рәсмиләштерv процедурасы алып барыла, соныннан аларны сату, аренда һәм салым алу рәвешендә әйләнешкә кертәләр. Бvгенге кондә урам яктырту белән бәйле кайбер проблемалар бар. Якын арада торак әһәмиятендәге биш юл участогын тиешле хәлгә китерv планлаштырыла: Аксеновка авылынын Школьная урамында съезд ясарга, Лопатино авылынын Үзәк урамынына вак таш япма салырга, Сыркыды авылынын Школьная, Центральная, Хади Такташ урамнарында чокыр ремонты ясарга.

Сvзен дәвам итеп, Фәрит Тагер улы Эртуганов Сыркыды татар авылы - жиде торак пунктнын административ vзәге: Майский поселогы, Лопатино селосы; кечкенә авыллардан - Черемушки, Аксеновка, Гальчевка, Зарубята, Шмидовка, ди. Алар барысы да бер-берсеннән шактый ерак урнашкан, әмма бу кvпмилләтле халыкнын - русларнын, мордваларнын, татарларнын, украин-нарнын, тажикларнын дуслыгына, бердәмлегенә ара ераклыгы комачаулый алмый. Авыл халкы торле форматтагы чараларда еш очрый: гражданнар жыены, жыелышлар, сайлау кампанияләре, тозекләндерv буенча омәләр, мәдәни вакыйгалар. Биредә йоздән артык авыл хужалыгы һәм эшкәртv сәнәгате, социаль олкә, мәгариф вәкилләре эшли, ике йозгә якын пенсионер яши. Сургодь топ

гомуми белем бирv мәктәбен Светлана Мостафина житәкли. Мәктәптә илле малай һәм кыз белем ала. Торак пункт территориясендә оч сәvдә ноктасы, ике ФАП, ике КДЦ, ике китапханә, ике почта элемтәсе бvлекчәсе эшли.
Бу матур урыннарда ундырышлы туфракта 188 гаилә шәхси ярдәмче хужалык алып бара. Үз ишегалларында, яхшы жиһазландырылган махсус биналарда алар йоз илле сарык, сиксән дvрт баш сыер асрыйлар, шуларнын кырык бишесе сыерлар, казлар, кvркәләр, vрдәкләр, тавыклар. Шунысын да билгеләп vтәргә кирәк, Игорь Букин, Ольга Князева, Саъди Саидвалиев социаль контракттан файдаланып, дәvләттән терлек сатып алуга тvләvсез субсидия алганнар.
Торак пункт жирләрендә МАПО «Торбеево» нен ике эре терлекчелек бvлекчәсе нәтижәле эшли; vсемлекчеләр 3500 гектар мәйданда жир сорvлекләрен эшкәртәләр. Сыркыды авылынын топ истәлекле урыны һәм анын визит карточкасы булып татар шигъурияте классигы Хади Такташнын йорт – музее тора. Педагогик хезмәт ветераны Равилә Алим кызы Коновалова саклык белән, бортекләп биографик һәм туган якны ойрәнv материалларын, танылган шагыйрьнен чын экспонатларын һәм XX гасыр башы рухын саклаган әйберләрне жыя. 2004 елда мәчет тозелә. Хәзерге вакытта биредә vз имамы юк, вакыт-вакыт вәгазьләрне чакырылган руханилар укый, ә андагы тәртипне жирле моселман дини торкеме рәисе Рашид Абидулла улы Коновалов мулла, ярдәмчесе Шамиль Рустаев белән саклыйлар. Рашид хәзрәткә мәчетне тотуда жәмгыять әгъзалары ярдәм итә. Ә Лопатино авылында чиркәv кvтәрелә. Ул мәхәллә кешеләре һәм хәйриячеләр, жирле vзидарә органнары ярдәме белән даими рәвештә реставрацияләнә һәм vзгәртелә.
Шулай итеп, рус, мордва, татарлар илендә Фәрит Тагер улы Эртуганов белән бергә яшьләр һәм авылда туганнар vз тамырларын онытмый. Алар һәрвакыт коч һәм илһам алу очен туган як бусагасына ашыгалар.

**Н.ХӘЛИЛ**